# СОВЕТ БОЛЬШЕКУРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## РЕШЕНИЕ
## КАРАР

**30 декабрь 2015 ел** **№28**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Зеленодольск муниципаль районы «Олы Карауҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10 статьясы нигезендә, Олы Карауҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының «җирле референдум үткәрүне оештыру турында» гы 2015 елның 28 декабрендәге 18 номерлы карары, Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 декабрендәге «җирле референдумны үткәрү инициативасы турында» гы 25 номерлы карары нигезендә Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы карар кабул итте**:**

1. 2016 елның 6 мартына Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2016 елда Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә килешәсезме?:

| № | гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме (сум) |
| --- | --- | --- |
| 1. | 1. Төзелеш, агымдагы һәм капиталь ремонт, автомобиль юлларын, ишегалды территорияләрен, кварталара юлларны карап тоту | 158 000 |

«ӘЙЕ» «ЮК».».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга:(http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Олы Карауҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка: Олы Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 нче йорт,Олы Кулбаш авылы, Подгорная урамы, 26 нчы йорт адресы буенча хәбәр итәргә..

**Олы Карауҗа**
**Авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.Г. Шакиров**